**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ИВАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная, д.1а, с.Ивашкино, 423113

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзек урамы, 1а йорт, Ивашкино авылы, 423113

тел./факс (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

16.03. 2020 ел № 161

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 мартындагы 77 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2018 елның 12 мартындагы 77 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 25 апрелендәге 84 номерлы, 2018 елның 27 августындагы 92 номерлы, 2019 елның 18 февралендәге 119 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 134 номерлы, 2019 елның 17 сентябрендәге

136 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6.1. бүлекнең 2 пунктчасын бәян итәргә: «3) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиленең рөхсәте белән;

в) «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар».

1.2. 7.2.3 пунктчаны бәян итәргә: «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге
Башлыгы, Советы рәисе Н.Н.Ефимов